СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

*21 ноябрь, 1998 ел.*
*ШИМБӘ*

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.* | *№ 133 (8290)* | *Бәясе билгеләнгәнчә*

## МӘҢГЕЛЕКТӘН ДӘШӘР ТАТАР ТЕЛЕ

***17 ноябрьдә республикабыз башкаласы Казанда "Татарстан Республикасында телләрнең торышы: бүгенгесе һәм киләчәге" дигән темага фәнни - гамәли конференция үткәрелде. Аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы "Татарстан халыклары телләре турында" Татарстан республикасы Законын гамәлгә ашыру Комитеты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссиясе, Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырды.***

Конференция эшендә катнашучылар көннең беренче яртысында биш секциягә бүленеп эшләделәр. Секция утырышларында Татарстан Республикасы мәгариф системасында телләр турында [...]нчалыкны тормышка ашыру, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруның телләр торышына бәйле проблемалары, Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чаралары эшендә һәм кулланучылар даирәсендә тел сәясәте мәсьәләләре, "Татарстан Республикасы халыклары телләре турында"гы Законны гамәлгә ашыруның методологик һәм лингвистик аспектлары тикшерелде.

Көннең икенче яртысында "Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Кече залында пленар утырыш булды. Утырышны Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р.М.Харисов кереш сүз белән ачты һәм алып барды. Пленар утырышта республика Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х.Мөхәммәтшин катнашты һәм чыгыш ясады. Утырышта телләр турында Законны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча резолюция кабул ителде.

Пленар утырыш барышында телләр турындагы Законның тормышка ашырылуын чагылдырган күргәзмәләр эшләде.

**("Ватаным Татарстан" нан).**

## ЫШАНЫЧЛЫЛАР ЗАТЫННАН



***Михаил Лапин кебекләргә һәрчак таянырга мөмкин. Аңа нинди дә булса эш тапшырасың икән, Михаилның аны җиренә җиткереп башкарып чыгасына шикләнмәскә була. "Нурлатнефть" НГДУсының технологик транспорт идарәсенә 18 ел элек урнашкан иде ул, һәм ныклы дисциплина хакимлек иткән коллективка бик тә үз килде Лапин. Башта озак кына вакыт зур габаритлы йөкләр ташый торган машинада эшләде, моннан ике еллар элек, идарәгә яңа техника кайткач, үзбушаткыч машинаны аңа бирделәр. Шул КамАЗы белән Димитровградка да, Чистайга да йөри ул, ерак рейсларга чыгарга машинасы һәрчак әзер була. Төзелеш материаллары ташый ул. Ә алар гел кирәк.***

***Рәсемдә: УТТның 1 нче колоннасы шоферы М.Лапин.***

***Н.АЗИЗОВ фотосы.***

## ШАРТЫ БУЛГАЧ, ЭШЕ ДӘ БАРА

"Чирмешән" агрофирмасының Салдакай бүлекчәсендә авыл хуҗалыгы техникасын, бигрәк тә тагылма эш коралларын язга әзерләү эшенең үрнәк төстә оештырылуы турында әйтүебез. Ремонт мастерскоеның барлык цехларында да эш кайный бүген. Тимерче Олег Матвеев белән Вячеслав Егоров һәм Александр Прокопьев тырмаларны әнә күзеннән үткәрсәләр, Валерий һәм Анатолий Васильевлар чәчкечләрне, Владимир Семенов һәм Сергей Галанцев культиваторларны төзәтү белән мәшгульләр. Ә инде эретеп ябыштыручы Анатолий Павлов аларның һәр үтенечен җиренә җиткереп үтәргә тырыша. Мастерскойда эш шартлары канәгатьләнерлек, теләгән кешегә төшке ашын да янәшәдәге ашханәдә ашап алырга мөмкин булгач, ремонтчыларның күңелләре төшенке түгел, шуңа эшләре дә ипле бара.

**Р.МУЛЛИН.**

### *Газлаштыру бара*

## ЯШЬ БУЛСА ДА ЯШЕЛ ТҮГЕЛ

***"Газпромстрой" берләшмәсе АҖ Нурлат участогының биографиясе әле зур түгел: ул 1997 елның 1 гыйнвареннан гына эшли. Сан ягыннан да ул 17 генә кешене берләштерә. Әмма шуңа карамастан, алар район газчылары отрядына кушылып, анда үзләренең лаеклы урыннарын табарга өлгерделәр инде. Участокның төп хезмәте - поселокара, поселок эчендәге газүткәргечләр, торак йортлар, котельнялар, ГРПлар монтажлау, газчылар корыч һәм полиэтилен торбалар белән эшләү тәҗрибәсенә дә ияләр.***

- Бүген безнең эш нигездә өч төбәктә бара: "Комбайн" КХАсының Иске Әмзә авылында, шәһәрнең тимер юлчылар поселогында торак йортларга газ кертелә һәм Заречный авылыннан Чуваш Тимерлегенә кадәр югары басымлы газүткәргеч сузыла, - дип таныштыра башлады участокның эше белән аның начальнигы Г.Н.Бикиниев.

Районның өч ягына сибелгән бригадаларның көйле эшен тәэмин итү, билгеле, җиңел түгел. Әмма район хакимияте башлыгының катгый таләбе бар: республика газлаштыру фонды эшләгәндә, районның иң ерак төбәкләренә кадәр газүткәргечләрне сузып калырга кирәк. Бикиниев оешмасы, башка газчылар кебек үк, шул катлаулы бурычны хәл итү өстендә эшли. Иске Әмзәдә алар икенче ел эш алып баралар инде. Биредә алар районда беренче тапкыр поселок эчендә газ сузуда полиэтилен торбалар кулландылар. Аның элек язылган өстенлекләренә тагын шунысын да өстәргә кирәк: полиэтилен торбалар җир астыннан сузыла, аларга терәк куюның кирәге юк. Бу исә материалларны да янга калдыра, еш кына килеп чыга торган терәккә бәрелү, авария очраклары да булмаячак, дигән сүз. Хәзер газчылар биредә тагын 31 йортка газ бирергә җыеналар, районның иң ерак төбәкләреннән саналган авыл халкы зәңгәр ягулыкка сөенеп туя алмый.

Шәһәрдә газ үткәрүнең үз нечкәлекләре бар. Участок егетләренә 2 елда шикәрчеләр бистәсенең Циолковский, Маяковский, Тукай урамнарының көнчыгыш өлешләрендә эшләргә туры килде. Циолковский урамында яшәүчеләр тулысынча газны алдылар, ә менә соңгы икесендә, заказчы түләү мәсьәләсен әлегәчә хәл итмәгәнлектән, газ рәхәтен күрүдән мәхрүмнәр. Кызганычка каршы, бу - бердәнбер очрак түгел. Карл Маркс проспектындагы ике торак йорт белән дә шулай булды. Заказчы - МПП газлаштыру өчен түләүне башкара алмаса да, ветераннар йортына участок узган ел (Җиңүнең 50 еллыгы бит!) газ бирә торырга ризалашты. Ә менә проспекттагы 1нче йортта яшәүчеләр торбалар сузылгач та газны ел ярым көтәргә мәҗбүр булдылар.

**(Ахыры 2нче биттә).**

### ** Мәгариф яңалыклары*

## СЕМИНАР - МӘКТӘП БАЗАСЫНДА

Шушы көннәрдә генә 4нче мәктәп базасында районның рус һәм татар мәктәпләрендә татар теле укытучыларының чираттагы семинары булды.

Катнашучылар башта өлкән укытучылар Н.С.Гайфуллина һәм Г.М.Таҗиев биргән ачык дәресне карадылар. Теоретик өлештә әлеге дәресләргә тулы анализ ясалды, район мәгариф бүлеге методик кабинет җитәкчесе В.М.Камалова аттестация үткәрү үзенчәлекләренә тукталды. Семинарга йомгакны район татар теле укытучыларының методик берләшмәсе җитәкчесе Р.С.Гыйлемшина ясады, ул милли тел укытучылары алдында торган бурычларны бәян итте.

## АЛЛЕЯ БУЛАЧАК

"Мәктәп йортларын гөлбакча итик!" Район мәгариф бүлеге ташлаган бу чакыруны 4нче мәктәп коллективы үзенчә кабул итте. Карт өянкеләр, мамык очырып йөдәткән тупыллар урынына декоратив куаклар утыртырга, дигән карарга килделәр. Һәм чыгарылыш класслар аллеясы булдырырга. Быел бу юнәлештә беренче адым ясалды да инде. 1999 елда мәктәпне тәмамлаячак унберенчеләр көзен махсус урынга 40 төп миләш утырттылар. Бу традиция ныгый китсә, тиздән мәктәпнең горурлыгы булып бик матур аллея барлыкка киләчәк.

## Ә ТЕПЛИЦАДА - ЯЗ

Тышта салкын кыш, ә мәктәп теплицасында - әйтерсең, ямьле яз: әнә розалар, каллалар күтәрелә, тюльпаннар чәчәккә бөреләнә. Быел кыш виктория, редиска да уңыш бирер, дип өметләнәләр. Ә суган, әнис, петрушканы һәр көнне аз - азлап сатып торалар, нефтебаза ашханәсеннән дә даими килеп алалар.

- Җәйге ремонттан соң шулай гөрләп үсә башлады барысы да, - ди теплица хуҗасы Т.Н.Белянина. Әйе, яшелчә, җиләк - җимеш җылыны ярата: җылы һаваны да, аны үстерүченең җылы кулларын да, җан җылысын да тиз тоя ул.

## УКУЧЫЛАР ЛЕКЦИЯДӘ

**16 ноябрьдән район мәгариф бүлеге Яшьләр үзәгендә мәктәп укучылары өчен икенче лекцияләр агымын башлады.**

Лекцияләрнең беренче агымы өлкән класс укучылары өчен уку елының башыннан ук үткәрелгән булса, бу юлы алар 5 - 6нчы класс укучылары өчен оештырылды. Балалар белән очрашуга район үзәк хастаханәсе педиатрлары, психологлар, район хакимияте каршындагы балигъ булмаганнар комиссиясенең секретаре киләләр. Педиатрлар, башлыча, тәмәке тартуның зарарлы булуын төшендерергә тырышалар, янап торган грипптан саклану чараларын аңлаталар.

Ә психологлар кыен очраклардан ничек итеп үзеңә дә, тирә - ягыңдагылар психикасына да зарар китермичә җиңел генә чыгарга мөмкинлеге хакында сөйлиләр.

Балигъ булмаганнар комиссиясе ягыннан аңлаешлы итеп, иң гади телдә, тәртип бозулар өчен каралган җәзалар турында әйтелә, бигрәк тә балаларның "шуклыгы" ата - аналарга кыйммәткә төшүе хакында төшендерелә. Киләсе атнадан укучылар алдында балалар китапханәчеләре дә чыгыш ясаячак.

Иң беренче көннәрдә лекцияләрне авыл мәктәбе укучылары тыңлый. Дөрес, бу "бәхет" бөтен авыл мәктәпләренә дә эләкми, хуҗалык җитәкчеләре ярдәмендә килергә җай тапканнары гына Нурлатта булуга ирешә, ә транспорт таба алмыйча килә алмый калган мәктәп укучылары да аз түгел. Ә килгәннәре лекция тыңлап кына калмыйлар, аңардан соң алар өчен дискотека оештырыла, аннары сәнгать мәктәбендә концерт күрсәтелә. Экскурсия "Нурлатнефть" НГДУсының бассейнында тәмамлана.

**Лекцияләр 10нчы декабрьгә кадәр дәвам итәчәк.**

## ИЛ СУЛЫШЫ

** Республикабыз студентларына Татарстан Фәннәр академиясе стипендиясен алу мөмкинлеге булдырылды.*

*Стипендияләр Татарстан "минималкасы" күләмендә - 350 сум булып, бәйге нигезендә бер семестрга, фәнни эшчәнлекләре белән аерылып торган студентларга биреләчәк. Ул гуманитар, табигать һәм техник фәннәрне күздә тота.*

** Республикабыз хаҗ кылучылары мөфти Госман хәзрәт Исхаков җитәкчелегендә Мәскәүгә очтылар. Соңыннан алар Согуд Гарәбстанына, Өмрә хаҗын үтәргә юнәләчәкләр.*

** Самара шәһәрендә яңа мәчет ачылу тантанасы булып узды.*

** Нижгар өлкәсе губернаторы Игорь Скляров җирле "Туган як" иҗтимагый - сәяси татар газетасы өчен 50 мең сум күләмендә акча бүлеп бирде. Редакция шунда ук эш өчен бик тә кирәкле компьютер техникасы, "УАЗ" машинасы сатып алды, татарча китаплар нәшер итү өчен лицензия бәясен тулысынча түләде.*

### *Газлаштыру бара*

# ЯШЬ БУЛСА ДА ЯШЕЛ ТҮГЕЛ

**(Ахыры. Башы 1нче биттә).**

Участок та үзләштерелгән күләм өчен акчаны шулкадәр үк көтте дигән сүз бит бу! Ә ул, үз чиратында, хезмәт хакы, материаллар, башка кирәк - ярак белән өзеклек китереп тудыра.

Участок егетләре тимер юлчылар бистәсен газлаштыру эшендә дә катнашалар. Бердән, алар Түбән Нурлаттан шәһәрнең Киров урамына кадәр югары басымлы газ торбасы (полиэтилен) суздылар, ике шкаф җайланмасы урнаштырдылар. Калинин, Линейная, Садовая, Овражная, Куйбышев, Л. Толстой урамнарындагы шәхси йортларны газга тоташтыру буенча эшләделәр, хәзер дә эшлиләр. Еш кына газчыларга йорт хуҗаларының шулай ук түләү мәсьәләсенә авырсынуына юлыгырга туры килә. Сүз дә юк, хәзерге шартларда акча мәсьәләсе күп нәрсәгә аяк чала. Әмма шунысы да бар: әлегә участок монтаж эшендә 1997 елгы бәяләр коэффициенты буенча эшли, һәм йортны газлаштыру бу бәяләр буенча 2,3 - 2,5 меңгә төшә. Ә киләсе елдан бу сумма 5 - 6 меңгә җитәчәк бит! Шуңа да газлаштыру эшен сузмау хуҗаларның үзләре өчен дә отышлы икәнен искәртәсебез килә.

Участокның өченче төп эш урыны - Заречный - Чуваш Тимерлеге трассасын сузу шактый кыен шартларда бара. Биредә сазлыклы урыннар күп, аларны үтү җиңел түгел. Шулай да Елаурга кадәрге төп трасса сузылган инде, хәзер ахыр пунктка кадәр 1 км. ара калып бара. Анысын ел ахырына кадәр тәмамлау бурычы тора. Ә бу арага трассаны үткәрүдә Елаурдагы В.Сайкин җитәкчелегендәге "Нива" кооперативының булышлыгын нык тойдылар газчылар. Авылга газ килүен тизләтү өчен булды, билгеле, ул ярдәм. Хәтерләсәгез, "Газпромстрой" начальнигы Р.Әхмәров тантаналы шартларда Елаурга газны республика суверенитеты - 30 август көнне бирергә җыенган иде. Хәзер аның сузылу сәбәбен бер сүз белән генә аңлатып та бирә алмыйлар, ул әллә никадәр төрле зурлыктагы сәбәпләрдән җыела. Әмма быел зәңгәр ягулык авылда һичшиксез кабыначак, диләр газчылар. Бусына инде үз көчләренә таянып вәгъдә бирәләр. Эшчеләрнең шактый тәҗрибәләре, осталары җыелган биредә. Эретеп ябыштыручылар Виктор Бикиниев, Алексей Трофимов, Федор Бикиниев, слесарь Эдуард Таймуллин - беренчеләрдән булып полиэтилен торбалар белән эшләү тәҗрибәсен үзләштергән кешеләр. Корыч торбалар ябыштыручылар Заһит Җәлалов, Дмитрий Бикиниев, Владимир Садовников һәм Владимир Рахчеев, слесарьлар Алексей Бикиниев, Вячеслав Анисимов, Альберт Насыйбуллинны җаваплылыкка, хезмәткә өйрәтәсе юк. Материаллар ташып торучы Юрий Дементьев та эштә өзеклекләр тудырмаска тырыша. Ә эшне финал ноктасына җиткерү техник документацияләр буенча инженер О.Н.Алферовага йөкләнгән. Азсанлы коллективның һәр әгъзасына шулай шактый йөк тартырга туры килә. Сүз уңаеннан, хуҗалыкның нульдән җыя башлаган материаль базасы да бик нык дип булмый әле. Махсус җиһазлар, эш кораллары белән тәэмин ителсәләр дә, техника ягы кысанрак: бер әрҗәле УАЗлары һәм "ЗИЛ - 131" машиналары гына бар. Дөрес, үзләренең конторaларын, склад белән берлектә гараж төзеп куйдылар. Куәтле техника кирәк булганда, заказ бирергә туры килә. (килешәсездер, бусы да эшне суза торган нәрсә!) Әмма ике генә ел яшәгән оешма үзенең төп бурычын гадел үтәргә омтыла. Бу хакта район хакимияте башлыгы урынбасары Н.Б.Мөлеков та әйтеп үтте. "Егетләр газлаштыруның хәзерге этапта никадәр мөһим нәрсә булуын аңлап әйбәт эшлиләр",- диде. Димәк, яшь булса да яшел түгел участок!

**С.ХӘЙРУЛЛИНА.**

## ЧУЛПАН УҢГАННАРЫ



***"Елның 365 көнен дә эштә инде ул",- диләр "Чулпан"да механизатор Хәкимулла Әхмәдуллович Нуретдинов турында. Чыннан да, аның карамагындагы ике техника да хуҗасының ипле кулы кодрәте белән тик торуны белмиләр. Җәй көннәрендә Нуретдинов СК - 5 комбайны белән кырлар иңли, игеннәрне тезәмнәргә сала. Янәшәсендә ышанычлы һәм алыштыргысыз ярдәмчесе - олы улы Ринат була аның. Сүз уңаеннан, 11 класста укучы үсмер 3 - 4 сезон инде штурвал янәшәсендәге урынны беркемгә бирми.***

***Урак сезоны бетүгә, Хәкимулла үзенең төягечле Т - 40 тракторына утыра. Кыш буе ул чирәмәсен дә чыгара, саламын да төйи, башка эшләрдән дә баш тартмый. Ә гаиләдә аның үз мәшәкатьләре, үз роле. Менә ничә еллар инде ул карт әнисе, ике малае белән яши, улларына ата тәрбиясе дә, ана җылысы да бирә. Әтиләренең игелекле холкын, эш сөючәнлеген күреп үскән балалар, билгеле, шулай ук хезмәткә иртә тартылдылар, тәртип - әдәп мәсьәләсендә дә сүз кузгатмыйлар.***

***Рәсемдәге икенче механизатор Евгений Александрович Суховның хезмәтенә дә тел - теш тидерә торган түгел. Ул МТЗ - 80 тракторында эшли, авыл хуҗалыгында һәр сезонлы эштә намус белән катнашып килә.***

***"Чулпан" КХАсының иң алдынгы механизаторларын фотохәбәрчебез Н.АЗИЗОВ кыска ял арасында фотога төшереп алган.***

### АЧЫКТАН - АЧЫК ӘЙТКӘНДӘ

# «КОМБАЙН»НЫҢ КАНАТЫ КАЕРЫЛА

Кайчандыр гөрләп торган, бигрәк тә терлекчелек өлкәсендә алдынгы хуҗалыклар чутында йөргән "Комбайн" да бүген хәлләр һич тә мактанырлык түгел. Ә терлекчелек кебек четрекле өлкәдә ирешелгән нәтиҗәләрне кискен киметүе генә җиңел бит ул, аннан элеккеге позицияләргә кире менү ай - һай авыр. Әнә бит, заманында дуңгызчылыкның тамырына балта чапкан кайбер хуҗалыклар хәзер бу тармакның төшемлелеген күреп, ул эшне яңартып җибәрмәкче булып ничек азапланалар, әмма эш узгач, терсәкне тешләп булмый шул. Менә шуларны уйлаганда "Комбайн"ның язмышы өчен борчылудан аерым сүз алуыбыз юкка түгел.

Моннан элек бу хуҗалыкта октябрь аенда барлыгы 22 бозау алынып, шул ук айда шул кадәр үк малның үлүе турында бик югары дәрәҗәдә җитди сүз булган иде. Баксаң, бу һич тә очраклы гына хәл түгел икән бит. Статистикага күз салсак (ә андагы саннарны райондагылар һавадан алып куймаган, ә "Комбайн"-ның үз белгечләре һәм җитәкчеләре тапшырган отчетлардан алып теркәгән), хуҗалыкта терлекчелектә эшләрнең һич тә алга таба түгел, ә кирегә китүен күрергә мөмкин. Моның өчен соңгы бер - ике елдагы күрсәткечләргә генә күз салу да җитә.

1995 елда хуҗалык 7440 центнер сөт җитештергән булса, икенче елны бу күрсәткеч бик кискен - 1186 центнерга кимеде. Дөрес, былтыр ул чигенешне артыгы белән каплый алдылар алуын, әмма сыерларның продуктлылыгы буенча хуҗалык арттан икенче урыннан югары күтәрелмәде. Быел ун айда бер сыерга күчереп исәпләгәндә дәүләткә сатылган сөт күрсәткече (хәзер нәкъ шул төп критерий итеп алына) буенча да "Комбайн" иң арттагылар арасында. Кызганычка каршы, хәлнең уңайланасына өмет тә күренми - бүгенге көндә биредән сөт - май комбинатына көнаралаш 6 - 8 центнер гына продукция китерелә.

Хуҗалыкта малларның продуктлылыгы түбән булуны әйттек инде. Әмма продукция күләмен сыерларның баш саны исәбенә дә шактый югары тотучы хуҗалыклар да бар бит. Кызганычка каршы, "Комбайн"да бу уңайдан да алга таба бернинди өмет күренми. Һәм бу гаҗәп тә түгел, чөнки 1996 елда 46 тананың берсе дә савым сыерлар рәтенә күчерелмәгән, былтыр да көтүнең 8 проценты гына яңартылган. Өченче ел мөгезле эре терлекләрнең баш саны йөз башка диярлек азайган. Отчетта быел ноябрь башына ул күрсәткеч былтыргы дәрәҗәгә җиткән булып күренсә дә, чынлыкта сыерлар да, мөгезле эре терлекләр дә азрак икән. Гомумән алганда, соңгы 5 елда биредә мөгезле эре терлекләрнең баш саны 500, шул исәптән сыерларныкы 73 башка кимегән. Хәер, хуҗалык бозау алу буенча районда иң арттагы урында бара икән, моның нәрсәсенә гаҗәпләнергә ди. Сиксәненче елларда йөз сыерга 97шәр, ә 1990 елда хәтта 103 бозау алып килгән хуҗалык өченче ел 40, былтыр 52 бозау белән калды, быел ун айда да бу күрсәткеч 49 гына булды (барысы дарайонда иң түбән күрсәткечләр). Өстәвенә, былтыр 80 баш, ягъни аннан элеккеге елдагыдан берьярым тапкырга күбрәк мөгезле эре терлек үлгән. Болай да сыерларның яртысы үрчем китермәгән шартларда (анысы туу белән диярлек үк үлгән бозауларны исәпкә алып тормаудандадыр дип уйларга кирәк), шулкадәр малның әрәм булуына юл куюны гафу итеп булмый билгеле. Сәбәпләрне әллә кайдан эзлисе түгел. Яшь бозауларны салкында асрау ысулы рәтләп кулланылмый биредә. Ә моннан элек, салкын метод кертәбез дип, бозау абзарларының тәрәзәләрен алып ташлау гына һич тә яңа технология кертү түгел, ә каш ясыйм дип күз чыгару гына булган, чөнки бозау караучылар ул башбаштаклыкның нәтиҗәсе нинди булуын яшермиләр. Ә бит ул алымны җиренә җиткереп һәм эзлекле кулланган хуҗалыкларда менә дигән нәтиҗәләргә ирешәләр. Ни хезмәт шартлары, ни җирләре ягыннан әмзәләрдән бер дә өстенлекләре булмаган РСУ ярдәмче хуҗалыгында, мәсәлән, былтыр йөз сыердан 96, быел ун айда 92 бозау алдылар. Менә шуңа да "Комбайн"да авыл хуҗалыгы җирләренең һәр йөз гектарына 17,6 мөгезле эре терлек туры килсә, тегеләрдә бу күрсәткеч 32гә якын. Һәр йөз гектарга сыерлар саны да "Комбайн"да 7,5 кенә һәм бу - районда иң азлардан. Заманында терлекчелек гөрләп эшләп торган, шул максатларга заманча абзарлары да корылган Чурабатыр авылында хәзер хуҗалыкның бер генә баш терлеге дә юк, шул исәптән сарыкчылыкның тамыры корытылган. Ә ике кулыңа бер эш тә табарга мөмкин булмаган авылда халыкның кәефе нинди икәнлеген чамаларга бик мөмкин. Әле ярый, бозауларга яфрак азык әзерләп бирергә ризалашканнар андагылар. Урманга терәлеп утырган авылда җәен - кышын мал асрап кына чыгасы да бит югыйсә. Ә хуҗалыкта хәзер үзәк фермаларда асрарга да маллар аз. Инде һич югы шуларына җитәрлек игътибар бирәсе иде дә бит, тик юк, терлекләрне карау һәм ашату технологиясе таләпләре җиренә җиткереп үтәлми әле. Сүз савым сыерларга, бозауларга карашка да, үстерү һәм симертү группасы малларын карау мәсьәләсенә дә кагыла. Бүген ничектер, әмма без булган чакта кайбер абзарлардагы пычраклыкка гына да ис китәрлек иде. Бары Иске Әмзәнең савым сыерлар абзарында гына тәртип күзгә ташланды. Ә инде озакламый шул савым көтүен тулыландырырга тиешле буаз таналарның нинди шартларда тотылуын сөйли башласаң... Карда читендәге сай утлыкларга салынган барлы - юклы азыкка алданып килер өчен буаз таналар корсак асларына җиткән пычракны ерып көч - хәл белән атларга мәҗбүрләр иде. Юньләп ашатылмаган да маллардан нинди бозау көтәргә дә, нинди сөт өмет итәргә ди соң инде. Нәсел эше дә тиешле дәрәҗәдә алып барылмый. Хәер, берүзе өч -дүрт кеше урынына чабарга мәҗбүр булган ветеринария табибы гына барысына да ничек җитешсен ди? Ә элеккеге зоотехник былтыр дуңгыз фермасы мөдире итеп куелган булган. Анысының гөнаһысына кермибез, әмма ул тармакның да тиз генә алга китәсе күренми әле. Сиксәненче елларда елына икешәр мең тирәсе дуңгыз баласы алынып килгән "Комбайн"да бүгенге көндә анасы - баласы бергә бары 400ләп дуңгыз бар- биш елда өч тапкырга кимегән! Былтыр 400ләп дуңгыз баласы алынса, шуның биштән бере кадәрле мал үлгән. Быел ун айда да 60 дуңгыз үлгән инде, ә алынганы былтыргыдан әллә ни артык түгел. Шуңа да хуҗалыкның ит җитештерү һәм аны сатуда күрсәткечләре мактанырлык булмауга гаҗәпләнәсе юк. Авыл хуҗалыгы җирләренең һәр йөз гектарына ит җитештерү бу хуҗалыкта иң түбәне - былтыргысы 11 центнерга да тулмый, быелгысы да шуннан әллә ни алын булырга охшамый. Йөз гектарларга күчереп исәпләгәндә дәүләткә саткан итләре дә районның уртача күрсәткеченнән өч тапкыр кимрәк. Быел исә дәүләткә ит сату былтыргыдан 13 тапкырга кимрәк, ә бит суярга озатылган мал саны бермә - бер арткан. Тик менә нәтиҗәсе генә?...

Югарыда язылганнар әле "Комбайн"ның терлекчелек тармагындагы хәле торышына өстән - өстән күз салып чыкканнан соң туган фикерләр генә. Ә мәсьәләне тирәнтенрәк өйрәнә калсаң?... Хәер, без анысын максат та итмәдек. Әле әйткән кадәргесе дә хуҗалыкның уң канаты булырга тиешле терлекчелекнең "каерылып" баруын чамаларга мөмкинлек бирә. Катырак каерсаң ул канатның сынып чыгуы да бар бит. Шуңа да әмзәлеләр эшне аңар ук җиткермәсләр дип ышанасы килә.

**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**

Юбилейлар Юбилейлар Юбилейлар

# ЙӨРӘК ҖЫЛЫСЫН БИРЕП



- Үз фәне буенча тирән белемле, дәресләрне мавыктыргыч итеп алып бара, һәр укучының ихтыяҗын һәм нәрсәгә сәләтлелеген белә, гадел, игелекле, юмор хисе дә ят түгел аңа,- өлкән класс укучылары үзләренең укытучыларына шундый бәя бирделәр. Юбилей көннәре якынлашканда, минем дә аның турында сөйлисем килә.

Ул - математика укытучысы Александра Михайловна Казакова. Менә 32 ел инде ул балаларны кызыклы һәм серле саннар дөньясына алып керә, үзенең мавыгучанлыгы аша һөнәренең әһәмиятлелеген исбатлый. Аңа эшлеклелек, үзенә һәм тирә - ягындагыларга карата таләпчәнлек, һәр баланың яхшы якларын күрә һәм ача белү сыйфатлары хас. Укучыларга карата мөнәсәбәте игелекле, күзаллавы киң, оештыру сәләте көчле. Нәкъ шул сыйфатлары аркасында ул мәктәптә укыту эшләре буенча директор урынбасары, класстан тыш һәм мәктәптән тыш эшләрне оештыручы булып эшли дә.

Быелгы уку елында да 10 - 11нче классларда математика дәресләрен алып бара. Анда җитди игътибар, җыйнаклылык хөкем сөрә, культуралы акыл хезмәтен күзәтергә була. Аның оста итеп иҗади хезмәтне оештыра, җитди дисциплина булдыра белүенә һәр укытучы кызыга.

Укытучының дәресләре күп төрле: зачет - дәресләр, зиһенгә һөҗүм дәресләре, КВН - дәресләр. А.М.Казакованың кул астында дидактик уеннар да җитәрлек. Ул экспериментлар үткәрергә ярата. Бүгенге көндә Пермь шәһәренең укытучы - новаторы Ю.А.Макаров тәҗрибәсен куллана. Балалар математика дәресләрен түземсезлек белән көтеп алалар, чөнки анда үз - үзеңне күрсәтергә, инициативаңны белдерергә, иҗади һәм зиһен ягыннан ачылырга, йомшак якларың белән көрәшергә дә мөмкин. Ә мәктәптә ел саен үткәрелә торган математика атналары - иң якты, кызыклы һәм, әлбәттә, тәрбияви дә, акыллы да. Һәм бу җәһәттән педагог Казакованың өлеше бик зур.

Александра Михайловнаның укучылары яхшы белемнәргә ия. Алгебра һәм анализ башлангычыннан күчеш һәм чыгарылыш имтиханнарында биремнәрне әйбәт эшлиләр, югары уку йортларына керү имтиханнарын да уңышлы тапшыралар. Хәзер аның укучылары арасында укытучылар, табиблар, инженерлар һәм галимнәр бар.

Аның 11 "Г"сы мәктәптә иң яхшы класслардан санала. Класс белән эшләүдә ата - аналар класс җитәкчесенең иң ышанычлы һәм төпле ярдәмчеләре булып торалар. Укучылары мәктәптә иң кызыклы эшләрдә актив катнашалар, ә класстагы чаралар ныклы әзерлектә үтә, оригиналь фикерләр әйтелә. Укучылар остазларына киңәш сорап киләләр, ә яшь укытучылар ярдәм көтәләр, чөнки Александра Михайловна бернинди үтенечне дә кире какмый.

Ул бик мавыгучан кеше. Күп укый, шигырьләр яза, матур җырлый, рәсем ясый, спектакльләрдә уйный. "Зарянка" вокаль группасында солист та ул - группа мәктәп кичәләрендә катнашучыларны һәрвакыт куандырып тора. Спорт белән дә дуслыгы бар, "Сәламәтлек" түгәрәгендә шөгыльләнә, волейбол буенча укытучыларның җыелма командасында уйный. А.М.Казакова 1992 елда "Ел укытучысы" республика конкурсында безнең район вәкиле булды.

Һәрвакыт ачык күңелле, эшлекле, җыйнак, энергияле, иҗади көче ташып тора. Шулкадәр оптимистлык, тормышны сөю кайдан килә бу хатын - кызга дип, безгә еш гаҗәпләнергә туры килә.

Хезмәтләре өчен Александра Михайловнага "Әйдәп баручы укытучы" дигән югары квалификация категориясе бирелде. Шуңа күпсанлы грамоталар, Рәхмәт кәгазьләре, медальләр һәм "Хезмәт Кызыл Байрагы" орденын да өстәсәк, аның хезмәте югары бәяләнде дияргә мөмкин. Ләкин иң зур бүләк - укучыларының хөрмәте һәм мәхәббәте, дип уйлый Александра Михайловна.

Кайсыдыр бер акыллысы укытучы - ул автор да, режиссер да, белгеч тә, педагог, психолог һәм үзе үк башкаручы да, дигән. Бу сүзләрне мин безнең Александра Михайловнага карата әйтелгән дияр идем.

60 яшьлек юбилее белән аны чын күңелдән котлыйсым килә. Без, коллегалары, аның һәрчак шундый ягымлы, энергияле һәм тормыш сөючән булып калуын телибез. Мәктәп һәм балалар нәкъ шундый укытучыларга мохтаҗ.

**Т.МАСЛОВА,**
**Нурлат шәһәренең 2нче мәктәп директоры урынбасары.**

# ТАБИБЛАР ДА ҮРНӘК ТҮГЕЛ



Төркия университетларының тыйбб факультетларында белем алучылар башка студентларга караганда тәмәкене күбрәк тарта, хәмерне күбрәк эчә. Булачак табибәләрнең 29,4 проценты тәмәке пыскыта, 42,3 проценты хәмер куллана.

Анталия. Монда урнашкан Ак диңгез университетының тыйбб факультетында укучы 119 студентның тәмәкегә, хәмергә, наркотикларга һәм кофеинлы эчемлекләргә мөнәсәбәте тикшерелде. Алынган нәтиҗәләр җитди уйланырга мәҗбүр итә. Университетка кергәндә 119 студентның 21,8 проценты тәмәке тарткан булса, бер ел эчендә бу сан 29,4 процентка кадәр арткан. Элек тәмәкегә якын да килмәгән студентларның 12,9 проценты югары уку йортына кергәннән соң тарта башлаган. Электән үк тәмәке тартучыларда үзгәреш булса да, ул бары тик тартылган тәмәкенең саны белән бәйле. Әгәр университетка кергәнче алар көненә 10 сигарет тартса, студент булгач бу сан 14кә кадәр үскән.

Тикшерү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, тыйбб студентларының 42,3 проценты хәмер эчә. Эчемлекләр арасында беренче урынны сыра тота. Бәхеткә каршы, студентлар арасында наркоманнар юк. Икенче яктан, университетта укый башлаганчы кофе эчмәгән яшьләрнең 43 проценты, студент булып алганнан соң, даими рәвештә кофе эчә башлаган.

Шунысы кызык: булачак медиклар башка факультетларда укучыларга караганда тәмәкесен дә күбрәк тарта, кофены да күбрәк эчә. Моның сәбәпләре итеп "яшь егетнең (яки кызның) яңа мохитка керүе, ата - анасыннан еракта яшәве, укуның авырлыгы, төрле шәхси мәсь[...]ләләр" күрсәтелә.

**("Заман - Татарстан"нан).**


## БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

### КЫЙММӘТЛЕ ДАРУЛАР

**СӘДӘФЛЕ МУМИЕ, ГРАНУЛАДА ЖЕНЬШЕНЬ, ПИХТА ҺӘМ ШАЛКАН МАЕ.**

**Женьшень** неврастения, йөрәк неврозы, баш авыртканда кулланыла.

**Мумие** ашказаны язвасы, бавыр, бөерләр, сидек куыгы авыртканда файдаланыла.

**Алисат** (патша сәдәфләре) гипертония вакытында кан басымын төшерә.

**Анкир** - диабетларны дәвалый, авырлыкны киметү, организмнан шлаклар һәм токсик матдәләрне кууга билгеләнгән.

Шулай ук **магнит билбаулары, беләзекләр, аслыклар** сатабыз.

***Бу даруларны сез район үзәк шифаханәсе поликлиникасында 25 ноябрьдә 9 сәгатьтән 13 сәгатькә кадәр ала аласыз. Барлык препаратларның да сертификаты бар.***

Лицензия номеры 000458.

### САТАБЫЗ

**"Нурлатнефть" НГДУсы халыкка һәм оешмаларга сатып алу өчен Әхмәт авылында төрле дәрәҗәдә әзерлектәге төзелеп бетмәгән торак йортлар тәкъдим итә.** Тел.: 2-22-84.

**Декабристлар урамында 70нче йорт. Пар белән җылытыла, челтәр газына тоташтырырга әзер. Йорт яны корылмалары, участогы, мунчасы бар. Бер яки ике бүлмәле фатирга алмаштырырга мөмкин.**

Тел.: 2-21-74, 5-21-86.

***

**Җир участогы, "Стинол" туңдыру камерасы, "LG" телевизоры.** Тел.: 2-12-53.

***

**Вишневая Поляна авылында дача итеп тотарга йорт.** Тел.: 5-16-35.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**Мәрмәр валчыкларыннан ике көндә язып биреп кабер ташлары, портрет төшерелгән гранит плитәләр сатам. Бәяләре килешү буенча.** Адрес: Ленинград ур., 14.

***

**Яңа Әлмәт мәктәбе тарафыннан 1996 елда Ренат Салих улы Нуретдинов исеменә бирелгән А сер.№ 1292191 аттестатын югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип исәпләргә.**


# ХУҖАЛАРЫ КАЙДА ИКӘН?



Мотоцикл, бигрәк тә авыл кешесенең яраткан транспорт чарасы. Еш кына шәхси ихтыяҗлар өчен нәкъ менә мотоцикл сатып алалар да. Тик бу әле аңарда теләсә кем иркенләп йөри ала дигән сүз түгел. Барлык транспорт чаралары кебек үк, мотоцикл да иң элек теркәлергә тиеш. Нәкъ менә шул таләп үтәлмәгән булу аркасында күп кенә мотоцикллар штрафлы саклау урынына эләгәләр дә инде. Моңа тагын бер сәбәп - руль артындагыларның аек булмавы. Быел ун айда гына да мотоциклда исерек килеш җилдерүче 30 кеше тотылган. Күбесенең корыч "атлары" әнә шулай кар -яңгыр астында күгәреп ята да инде, чөнки хуҗаларының бу мотоциклга нәкъ менә алар хуҗа икәнлеген раславрга тиешле документлары юк.

Ә штрафлы саклау урынында 6 айдан артык торган транспорт моннан ары хуҗасыз дип таныла һәм картинг -клубларга тапшырыла.

Шуңа да кем генә булса да берәр төрле транспорт чарасы сатып ала икән, ул аны һичшиксез теркәтергә тиеш. Ул вакытта ЮХИДИ белән сезнең арада бернинди аңлашылмаучылыклар да булмас.

**Г.ГЫЙМАЛЕТДИНОВА.**

# КИТАП БЕЗГӘ КУНАККА КИЛЕР



Күптән түгел шәһәр балалар китапханәсендә яшь укучылар өчен төрле мавыктыргыч чаралар үткәрелде. Ике көнгә исәпләнгән программа "Әдәби геройларны танып бел" дигән викторина һәм тартмачык (анда балалар үзләренең яраткан чәчәкләрен җыйдылар) уены белән ачылды, төрле уеннар, конкурслар, мәзәкләр булды. Уеннарда Д. Стрельникова (1нче мәктәп), бертуган Мусаевлар (3нче мәктәп), Гришовлар һәм О.Камышина (4нче мәктәп) бик актив катнаштылар. Җиңүчеләр фломастерлар җыелмасы һәм бик матур китаплар белән бүләкләнделәр, соңыннан барысы бергә дискотекада күңел ачтылар. Икенче көнне укучыларның игътибарын Николай Носовның 90 еллык юбилеена юнәлдерделәр. Балалар китап күргәзмәсе белән таныштылар, "Фонтазерлар" китабының геройларын, Белмәмеш, Беләмән, Пончик һәм башка геройларның маҗараларын искә төшерделәр. Китапханә коллективы үзләренең укучылары өчен ноябрь аенда 70 яшен тутыручы балалар язучысы Шәүкәт Галиев китапларыннан күргәзмә әзерләгән иде. Балаларга уку өчен китаплар "Мин сәламәтлегемне саклыйм - үземә - үзем булышам" дигән темага "Синең үзең турында", "Сәламәтлек дәресләре", "Татып карамаска! Башламаска!" (алкоголь һәм наркотикларның зыяны турында) бүлекләре буенча әзерләнгән иде.

**Т.АЛЕКСЕЕВА.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**


**Учредительләр: Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19. Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2361 данә. 4407